КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 63

2023 елда, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны үткәрмичә, генераль планнарга, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә генераль планнарга үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны үткәрмичә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

расланган Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру документларына, Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасына туры китергәндә;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына белешмә кертү өчен кирәк булган торак пунктлар чикләрен төгәлләштергәндә;

элек билгеләнгән тәртиптә расланган генераль планнарда урнаштырылуы каралган территорияләрне планлаштыру буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы яки ачык тыңлаулар процедурасын үтеп расланган документацияләр нигезендә гамәлдәге яки планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге линия объектлары, төбәк әһәмиятендәге линия объектлары, җирле әһәмияттәге линия объектлары урнашу урынына үзгәреш керткәндә;

социаль инфраструктура объектларын, федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган программаларда, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясамый торган,

Россия Федерациясе Җир кодексының 105 статьясы нигезендә территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар билгеләү каралмаган табигый монополияләр субъектларының, коммуналь комплекс оешмаларының инвестиция программаларында каралган объектларны урнаштырганда;

әгәр җир кишәрлегенең барлык чиге торак пункт чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре белән чиктәш булса, җир кишәрлекләрен урман фонды җирләреннән торак пунктлар чикләренә кертү максатларында торак пунктлар чикләренә үзгәреш керткәндә;

территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашырганда;

масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда;

илкүләм проекты составына керә торган федераль проектларны гамәлгә ашырганда;

«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән төзелгән килешүләр нигезендә төзелеше инвесторлар көчләре белән һәм (яки) аларның акчасы белән җәлеп итеп гамәлгә ашырылган күпфатирлы йортлар төзелешен, шулай ук мондый килешүләрдә күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) объектлар төзелешен тәэмин иткәндә;

ике һәм аннан да күбрәк функциональ зоналарда җир кишәрлекләре урнашуны бетергәндә.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны үткәрмичә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

расланган территориаль планлаштыру документларына кертелгән федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру максаты белән территория зоналарын, ярдәмче зоналарны үзгәрткәндә (билгеләгәндә), шәһәр төзелеше регламентларына үзгәреш керткәндә;

федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән тормышка ашырыла торган программаларда төзелеше, реконструкциясе, модернизациясе, заманча файдалануга җайлаштырылуы, булдырылуы каралган федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру максаты белән территория зоналарын, ярдәмче зоналарны үзгәрткәндә (билгеләгәндә);

расланган генераль планга туры китергәндә;

территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашырганда;

масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда;

илкүләм проекты составына керә торган федераль проектларны гамәлгә ашырганда;

«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль

законда каралган проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән төзелгән килешүләр нигезендә төзелеше инвесторлар көчләре белән һәм (яки) аларның акчасы белән җәлеп итеп гамәлгә ашырылган күпфатирлы йортлар төзелешен, шулай ук мондый килешүләрдә күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) объектлар төзелешен тәэмин иткәндә;

ике һәм аннан да күбрәк территория зоналарында җир кишәрлекләре урнашуны бетергәндә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин